| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Брюшлинского сельского поселения Менделеевского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советы |

Решение
2021 елның 12 апреленнән

Карар
№ 27

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2018 елның 19 сентябрендәге 101 номерлы Бөрешле авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 12 статьяның 3 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3_1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә.»
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» киләсе веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә киләсе веб-адрес буенча урнаштырырга: https://mendeleevsk.tatarstan.ru.

Бөрешле авыл җирлеге
Советы рәисе Л.А. Смирнова